# ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА

# Тынлык кайтавазы

*Шигырьләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г92

**Гыйбадуллина, Л.Ф.**

Г92 Тынлык кайтавазы : шигырьләр / Лилия Гыйбадуллина ; кереш сүз авт. Л.Шәех. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 39 б.
ISBN 978-5-298-01831-9

Әлеге китапта яшь шагыйрә Лилия Гыйбадуллинаның соңгы елларда язылган лирик һәм фәлсәфи шигырьләре урын алды.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01831-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Гыйбадуллина Л.Ф., 2010

# Табигать кызы

Лилия Гыйбадуллина шигырьләрен укыганда, күңелне ниндидер татлы сагыш, ихлас хисләр өермәсе, табигатькә, яшәешкә булган мәхәббәт ташкыны биләп ала. Үзең дә сизмәстән, шул халәткә кереп китәсең һәм шагыйрә кичергән тойгылар белән бер дулкында тирбәлә башлыйсың.

Лилия – авыл кызы, табигать баласы. Аңа шәһәр ыгы-зыгысы, таш кала шау-шуы бөтенләе белән ят. Шулай булмаса, шагыйрә күңелендә югары дәрәҗәдә романтик, эчкерсез һәм ихлас шигырьләр ярала алыр иде микән?.. Юктыр.

...Ә очасы килә
Колач җәеп,
Үчекләп бер зәңгәр күкләрне...
Нәрсә булды бу тилергән җанга,
Мин җир кызы идем,
Күптәнме?..

Әйе, Лилия – җир кызы, ләкин аның уйлары, хыяллары биектә, җиде күк катында. Очасы килә икән, ул оча, колачын киң итеп җәеп ак болытлар арасында йөзә, «язларга яланаяк чаба», «моң булып түгелә». Шагыйрә үзе дә:

Ак болыт юллары һавада,
Ә җирдә төсләрнең бураны.
Өметкә күмелгән язларда
Күкләргә омтылмый буламы?
Хыялда онтылмый буламы?.. –

дип яза.

Тора-бара табигатьнең гүзәл мизгелләрендә туган хыяллар конкретлаша. Гадәти, әмма үзенчәлекле һәм яңача фәлсәфә сату булып күренгән шигъри юллар йөрәкнең иң яшерен төпкеленнән ургылып чыккан мәхәббәт һәм халык язмышы, милләтнең бүгенгесе һәм үткәне белән алышына:

...Ә син мине ярат!
Күзләреңә карап,
Язмышыңны үзем юрармын...

Йә булмаса:

Мең чыбыркы ысылдавы җилдә
Хәрабәләр һәйкәл булган илдә.

Лилия Гыйбадуллина шигырьләрендә әлегә баш югалтырлык көчле сөю күзгә бәрелеп тормый, ә мәхәббәтне танып белергә омтылу адымнары, беренче җитди тойгылар ярылып ята. Рухи «мин»нән «син»гә күчү башланган инде, шулай дәвам итәр дип ышанам.

Тагын шунысы үзенчәлекле: бу китапта урын алган шигырьләр арасында берсенең генә дә исеме юк. Шагыйрә үз хисләрен билгеле бер кыса эченә кертеп утыртырга теләми, ә аларның бәйсез, ирекле булып калуларын тели, күрәсең.

Әйткәнемчә, Лилия – табигать кызы. Шагыйрәнең кайсы гына шигырен алма, анда – күк, болытлар, йолдызлар, кояш, ай, йолдыз, җил... Алар төрле формада һәм төрле халәттә. Л.Гыйбадуллинаның шигъри фантазиясе, үзенчә, романтикларча дөньяны күзаллавы алда санап үтелгән образларны кабатланмас итә: «Ай – кәгъбә ташы ул каралган, Йолдызлар – пыяла...», «Каурыйкаурый болыт...», «Челтәр-челтәр болыт...», «Кыйгач-кыйгач болыт...», «Иләс җилнең тыны туздырмасын Үткәннәрнең үксез көлләрен...», «Телем-телем кояш тәрәзләрдә...» һ.б.

Әйе, Лилия Гыйбадуллина әдәбият мәйданына үз сукмагы, үз образлары, беркемнекенә дә охшамаган шигырьләре белән килә. Бары үзенең кыйбласыннан тайпылмасын, хисләр коесын саектырмасын, яңадан-яңа әсәрләре белән безне сөендерүен дәвам итсен ул! Мин аңа каләмдәше буларак кына түгел, якташы буларак та уңышлар һәм илһам телим!

*Ленар Шәех*

* * *

Эх!
Хисләргә җигелеп,
Чикләрне җимереп
Чыгасы иде бер урамга
Котырган буранда!

Дөньяны ак төсләр күмгәндә,
Кемнәрдер елмаеп туганда,
Кемнәрдер елмаеп үлгәндә,
Гайбәткә карамый,
Сүзләрне аямый
Чыгасы иде бер урамга
Котырган буранда!

Чыгасы иде бер урамга,
Чыдасы иде бер буранга!..

* * *

Җир караңгы,
Күк караңгы,
Төн караңгы.
Юлга чыкты тынгысыз җил –
Төн карагы...

Күктә йолдыз бүген ничә?
Меңәрләгән иде кичә.
Йолдыз чүпләп караңгыдан гомер кичә...
...Ә җил исә һаман исә, һаман исә...

Пычкымыни – ялгыз айны болыт кисә,
Нишләр җиһан, бу гөнаһын сизсә?
Нишләр галәм, төнге күктән ай да бизсә?..
...Ә җил исә һаман исә, һаман исә...

* * *

Соры томан арада,
Күк ярлары аллана.
Ә төн, ай-һай, кара ла...

Таң җиле юлда уйный,
Сулыгып йолдыз сулый,
Һәр нурдан кояш ургый,
Иртәнге чыкны урлый.

Сүзләрне күзләр күмә,
Ялгыш эндәшә күрмә...
Күңел дөньяны күрә,
Юллардан еллар үрә...
Елмаям шуңа күрә...

* * *

Аклык.
Кочагына бар төсләрне,
        бар исләрне,
        бар хисләрне
Тамчы-тамчы җыйган да ул
Җәйрәп ята бар җиһанда
        Аклык тулы тынлык,
        Аклык тулы бушлык,
        Аклык тулы давыл...

Шул аклыкка терәлер дә
Мәңгелеккә,
Мәнлелеккә
Меңәрләгән
        дәвер авар...

* * *

Ак болыт юллары һавада,
Ә җирдә төсләрнең бураны.
Өметкә күмелгән язларда
Күкләргә омтылмый буламы?
Хыялда онтылмый буламы?..

Ак болыт эзләре җирләрдә.
Бу агым мәңгелек, мәңгелек...
Кайтаваз кайтара сүзләрем,
Чиксезлек ярына бәрелеп.

Күкләргә тулышкан зәңгәрлек
Бик гади, бик ерак, бик якын...
Ак болыт юлында җырлармын
Өметкә күмелгән яз хакын...

* * *

Төн инде.
Кил, сөйлә җилләргә,
Язмышың ачысын ай алыр,
Хәсрәтең түгелгән күңелең
Буш калыр...

Курыкма,
Кил, сөйлә җиһанга,
Ялгышың күкләргә сыяла...
Ай – кәгъбә ташы ул каралган,
Йолдызлар – пыяла...

Төн әле,
Кил, сөйлә җилләргә,
Язмышың ачысын ай алыр.
Таңнарда тауларга бәрелеп,
Сагышың кайтаваз кайтарыр,
Кайтарыр...

* * *

Кагылма син аңа,
Ул – минем сагышым,
Шул сагыш артыннан
Урау юл барышым.

Юлымда ак томан,
Болыннар, үзәннәр,
Өметләр, ялгышлар,
Тереләр, үлгәннәр...

Кагылма син аңа,
Юлларым адашыр,
Бәхетем нурыннан
Күзләрем камашыр...

Синең үз хыялың,
Минем үз язмышым...
Кагылма син аңа,
Ул – минем сагышым...

* * *

...Ә очасы килә
Колач җәеп,
Үчекләп бер зәңгәр күкләрне...
Нәрсә булды бу тилергән җанга,
Мин җир кызы идем,
Күптәнме?..

Ә очасы килә
Каурыйларны
Коя-коя ташлы юлларга...
...Син яварсың, яңгыр,
Тик иртәгә.
Соңга кала күрмә
Еларга...

Ә очасы килә
Ак болытны
Йомшак түшәк итеп уйнарга.
Кояш көлә.
Тәрәзәне яптым...
...Кала исе сеңгән уйларга...

* * *

Яндыр әле ялкыныңда, яңгыр!
Көйдер әле, калыйм тамчыга.
...Биткә бәргән яфрак җилләреннән
Талчыга күк йөрәк, талчыга...

Яндыр әле ялкыныңда, яңгыр,
Югаласым килә күзләрдә.
Соры күккә төбәп яшьле күзен,
Яфрак сулый минем эзләрдә...

Яндыр әле ялкыныңда, яңгыр!..
...Ачты болыт шыксыз кочагын.
Тыным итеп күз кабызыр кебек
Һәр тамчыда ярсу учагын...

* * *

Яшьләреңдә – узган еллар кере...
Алда – җәйләр,
Син борылма кире!..

Нахакларның хактыр меңнән бере...
Уян әле,
Син бит тере, тере!!!

Күзләреңдә – күзнең тансык сере...
Язлар узган,
Борыласы булсаң, борыл кире!
Борыл кире!..

* * *

Ярым ташу,
Ярым саташу бу –
Яфрак тулы җилләр дулкыны.
Бәргәләнәм сагыш дәрьясында,
Күзләр дулкынында упкынмы?..

Ярым яну,
Ярым таяну бу
Еллар ярындагы ялкынга...
Кояш нуры эзлим һәр караштан,
Юк, күнегә алмам салкынга.

Ярым җую,
Ярым җуелу бу,
Томан булып калу таңнарда.
...Мөлдерәмә тулып өмет ага
Яфракларда – күзге салларда.

Ярым качу,
Ярым качырылу,
Күмелә лә дөнья моңнарга...
...Теләсәм дә, рөхсәт итмәс йөрәк
Күзләр хозурына соңларга...

* * *

Җирдә әле көзләр...
Үзәгеңне өзәр
Яфракларның соңгы сулышы...
Ниләр эзли икән соры болыт,
Тар күкләргә тулып-тулышып...

Җирдә әле көзләр...
Тимәсен лә күзләр
Йолдызлардан койган яңгырга.
Әзер йөрәк
Көзләр учагында
Соңгы яфрак булып янарга...

Җирдә әле көзләр...
Артык, ахры, сүзләр...
Карашларда сагыш сурәте...
...Тынчу тынлык чолгынында йөрәк,
Җир тузаны кирәк, күрәсең...

Җирдә әле көзләр...
Ташта калган эзләр...
Актарылыр яфрак көртләре.
...Мин бик тиздән кабат кайтырмын күк,
Көзләр булып мине көт әле...

Җирдә әле көзләр...
Көзләр ничек түзәр
Ачылалмый калган серләргә?..
...Учларыма сары яфрак алдым
Тылсымлы төш итеп сөйләргә...

* * *

...Еракта бу тынлык,
Сулышы тирәндә...
Тынлыкка сусаган
Кайтаваз тирәндә...

Еракта бу сагыш,
Зәңгәр бәс – учларда...
Тик бер тын җитмәгән
Кайрылып очарга...

...Еракта бу сүзләр –
Упкынга убылган...
...Син җылы эзләгән
Соң мизгел – Ул булган...

* * *

Сорылыкка сарылды да
Сыкрады җан...
Тилерде аң,
Ал нурларын кочып таңның.
...Кояш идем,
Яндырам дип дөрләдем дә,
Куырылып,
Тик бер тамчы булып тамдым...

Белмәдемме
Саф җилләрнең керле исен,
Юллар җырын,
Сүзсез күзнең
Төче хисен...
Миңа тиеш зәңгәр хыял горур башын,
Таң йолдызы атылганда,
Күккә исен...

* * *

Бу җиһан, бу галәм, бу җирдә
Кирәкми берни дә, берни дә,
Тик бул Син!..
Башымны югалтыр сафлыкка,
Язларны елатыр аклыкка
Мин сине тиңләрмен,
Мин сине күкләрдән эзләрмен...
Югалма!
Һәр гомер, һәр дәвер, һәр мизгел
Болытка уралган булса да,
Еллардан ерганак – ак юллар
Җил белән чакырып торса да...
Онытма,
Җаннарның җыр тулы җылысын
Ташласам офыклар үренә,
Таңнарда тын томан торганда,
Адашсам аклыкның үзендә,
Күк булып багармын күзеңә...
Ышан син!..
Хәтта мин Яшәүгә ышанам...
Мин – күктән күчмәгән кош һаман,
Ә күкләр яшәүгә охшаган...

* * *

Сукыр җырчы
Сукыр җырын җырлый...
Сукыр карлар ява күкләрдән...
Ал күзлекләр киеп,
«Кышлар ап-ак!» диеп
Әйтүләрен көнли үткәннән...

Сукыр җырчы
Сукыр салкыннарда
Җылы эзли, язлар яктысын...
Әйт, яшермә,
Сансыз хыялларны
Кемнәр учак итеп якты соң?..

Сукыр җырчы
Сукыр чорлар аша,
Җырлар ашаниләр күрәдер?..
Ап-ак карлар белән,
Таңнар белән
Сукыр мизгелләрен күмәдер...

* * *

Вакыт үзе чиксез бер мизгел...
Нинди буш тар куыш – күңелем.
Язмышка юрапмы җырымны,
Чың тулып, моң булып түгелдем...

Бу гомер – чиксез бер табыну,
Абыну суларга, утларга...
Шашынып тибүе йөрәкнең
Алданып юл барга, Ул барга...

Тын алу – өметле көрсенү,
Уфтану Мәңгелек узганга...
Һәр чиксез дәвер дә язылыр
Кузларга әйләнер тузларга...

Һәр мизгел – чикләнгән бер Вакыт,
Тыныңа тәңгәлдер сулышы...
...Мизгелләр, чиксезлек янында,
Кояшка үрелгән кул ише...

* * *

Мин язларны сиңа бүләк итәм,
Сиңа бирәм көзләр сихерен.
Башым күккә тисә, йолдыз явар,
Ахры, артык биек сикердем...

Мин көннәрне синең өчен саныйм,
Мизгелләрне тезәм бушлыкка.
Хыялларым елап калыр кебек,
Ничек сыйыйм бу тар тышлыкка?

Мин җанымны сиңа атап сулыйм,
Ә син кайтыр өчен кит тагын...
...Мин – яңа җыр заман шаукымында,
Ачтым гына Яшәү китабын...

* * *

Мин язларга яланаяк чабам,
Сәлам биреп кала көннәрем.
Аптырама җүләр йөрәгемә,
Елармын да шашып көләрмен.

Хыялымда яз сулышын тоям,
Зәңгәр канатларым – иңемдә.
Юлларыңа йолдыз койсам әгәр,
Янарсың бит, зинһар, иелмә!..

Күзләремдә тамчы сафлыгы бар,
Битләремдә – шәфәкъ алсуы.
Мин язлардан нидер көтәм кебек,
Йөрәгемдә – Язлар ярсуы...

* * *

Бу – кояшлы төнме,
Айлы көнме?
Бәхет микән,
Ачы газапмы?
Мизгеллекме,
Мәңгелекме бу өн?
Әсирме син,
Әллә азатмы?

Китәсеңме
Яки кайтасыңмы?
Сорылыкка тарган
Җанмы син?
Ал таңнарга ашар
Өметме син?
Йә бөтенләй юкмы,
Бармы син?

Ялганмы син,
Ачы чынбарлыкмы?
Еракмы син,
Әллә якынмы?
Март аенда яуган
Ак кармы син?
Йолдызларны ялмар
Ялкынмы,
Мәхәббәт?!

* * *

Пәрәвез җебендә
Мең йолдыз чагыла,
Тар күкнең
(Бүгенгә бар күкнең)
Үзәге өзелер чагында
Яңгырдан…

Чакрымнар үтәли
Чәчемә сарыла
Әнием сулышы
Җай гына…
«Җангынам…»
…Сагынам…

* * *

Ачык тәрәзәләр.
Үтәли җил.
Ап-ак караңгылык,
Соры өн…
Трамвайлар җыры,
Зәңгәр күкләр,
Таш баскычлар…
Ардым…
Язгы көн…

* * *

Дулкын-дулкын упкын.
Җилкәннәрне оныт...
Убылыплар упты
Каурый-каурый болыт...

Дулкын-дулкын упкын...
Хәтсез хәтер булып,
Ишелде дә Тынлык,
Ярларыннан кубып,
Акты Вакыт, тулып...

Дулкын-дулкын упкын.
Упкын-упкын дулкын...
...Аңла Яшәү холкын...

* * *

Йөрәгемне урталайга телә
Тәрәзәдән төшкән кояш нуры.
...Күкрәү булыр очкыннардан куркам –
Күзләреңә карый алмыйм туры...

Һәлакәткә илтер упкыннар бар,
Тик бер адым... Җаным тетрәү тулы...
Хыял булыр чынбарлыктан куркам –
Күзләреңә карый алмыйм туры...

Чиксезлекнең кыл уртасын иңли
Офыкларга илтер гомер юлы...
Мизгел булыр мәңгелектән куркам –
Күзләреңә карый алмыйм туры...

* * *

Күкләр биек.
Учларымда тоям
Хыялларның төссез тузанын...
Беркем күрми,
Беркем белми калды
Ак буранлы юлдан узганым...

Күкләр биек,
Җирләр артык түбән...
Ал офыклар тәрәз артында.
...Мин күкләрнең җиде катында күк,
Мин күкләрнең җирге катында...

Күкләр биек.
Алар мәңгелеккә
Ерак булыр өчен яралган...
Күкләр булса,
Җирдә калалмам күк,
Күкләр булса,
Җирдә каралмам...

Күкләр биек,
Ак канатлы болыт
Карашларны назлап үпкәндә.
Күкләр биек...
...Елмаермын кебек,
Офыклардан атлап үткәндә...

* * *

Бәхетем тузаны, томан күк,
Һавага тарала таңнарда.
Мең таулар кичәргә кирәктер
Күңелем күкрәвен аңларга...

Ак яулык очырдым кичләрен
Ак кыя башыннан упкынга...
Аҗаган эзләре йөрәктә –
Тоташтан ут кына, ут кына...

Төннәргә күмелгән чиксезлек
Офыктан кул сузым арада...
Йолдызлар атылыр чагында,
Ымсынып күкләргә карама.

Тик синең күзләрдән эзләдем
Яшәүнең ялкынлы үзәген.
Бу тормыш – мәңгелек тораташ,
Мин генә нигәдер үзгәрдем...

Язларны узгач та юллар бар,
Һәм ерып чыккысыз кар анда...
...Күкләрдән мең йолдыз атыла,
Тауларны ак томан сарганда...

* * *

Тын алуым, соңаруым аша
Сиңа дәшәм, өнсез өмет булып...
Хыялларның аръягында томан,
Сыкрый сыман күкләр, әрнү тулып...

Хыялларның аръягында – Яшәү...
Кайтавазлар булып кайтам сиңа.
Җаным минем – дөрләр ялкын, ахры,
Бер чигенү аша мең талпына...

Җаным минем – сөюдәге нокта.
Каерылдым вакыт агышыннан...
Киләчәккә кайтам сине эзләп,
Диңгезләрдән качкан агым сыман...

Киләчәккә кайтам сине эзләп!..
Сызланулар, соңарулар булып.
...Хыялларның аръягында томан,
Сыкрый сыман күкләр, әрнү тулып...

* * *

...Ә син мине ярат!
Күзләреңә карап,
Язмышыңны үзем юрармын...
«Күзләр елак...» димә,
«Язлар ерак...» димә,
Мин күзләрдән сине урлармын!..

Ә син мине ярат!
Хыялларым – канат,
Мин күкләрне мең кат урармын...
«...Икебезгә җирдә
Һава җитмәс...» димә,
Мин сөюең белән сулармын...

* * *

Күкнең күкрәгенә хәнҗәр кадап,
Җиргә кояш кояр көннәрем.
Иләс җилнең тыны туздырмасын
Үткәннәрнең үксез көлләрен...

Ташуларга ташланырга әзер
Челтәр-челтәр болыт – күкләрем...
Мин, талчыккан тозлы тамчы булып,
Мең гасырлар моңын күтәрдем.

Сынмаска дип сабырлыкмы сыкрый,
Вакыт ярларына уралып...
Өмет булып чынга аша яшәү,
Язгы саташудан юралып...

* * *

Шартлап Вакыт өзелерлек Тынлык...
Онытылып килә отыласы...
Мең үрләрдән күкрәр кайтавазга
Бер йотым тын булып йотыласы...

Мең ярадан яралырлык итеп
Юраласы килә, югаласы...
Үзәкләргә үтәр үкенечтәй,
Вакыт ярларына ураласы...

Чиксезлекнең чикләренә җитеп,
Чигеш булып килә уеласы,
Тын төннәрдә ачык тәрәзләргә
Йолдыз булып килә коеласы...

...Шартлап Вакыт өзелерлек Тынлык
Йөрәкләрнең тигез тибешендә...
Онытылыр өчен отылдыкмы
Хәтерләрнең хәтәр чигешендә?..

* * *

Син мине очарга өйрәт тә
Юл күрсәт болытлар эзеннән…
Офыклар күкрәве – әрнү ул,
Күңелем түреннән өзелгән.

Ә күкләр хозуры мәңгелек.
Бу дөнья яралган болыттан…
Томанлы чиксезлек ярында
Мин сине онытмам, онытмам…

Талпыныр үрләрем күтәдер,
Китәмен йөрәгем канатып…
Яшенле яңгырлар, үчегеп,
Чылатыр минем ак канатым…

Күзләре әрнетер җанымны,
Төшермә җирләргә кабаттан.
Тик тыңла офыклар авазын:
«Мин сине яратам, яратам…»

* * *

Томан түгел, төсләр төенләнгән...
Тояр-тоймас тәме алмаларның...
Давыл булып дулар дөнья өнен
Тыңлаганчы укмы аңлаганмын...

Ефәк ятьмәләрдә ята йөрәк...
Күккә карыйм. Аягүрә дөнья...
...Хыяллар да җитмәс биеклектән
Кемдер тоя мине, кемдер тоя...

Яшеннәрдә – дуамал бер күкрәү.
Сискәнәсе килә сизгерлектән...
Ә вакытлар ватык. Үлчәмнәр юк...
Курка кыргый җаным. Синсезлектән...

Юк, иелеп алмыйм алмаларны...
Томан түгел, төсләр төене бу...
Иректәге сәгать укларының
Ятьмәләргә яткан көедер бу...

* * *

Кыйгач-кыйгач болыт күктә генәй!
Карлыгачлар канат кага микән?..
Канатларың каерылган чакта
Дүрт ягың да кыйбла кала микән?..

Томырылып аткан таңнарны да
Кыяр-кыймас кырау сара микән?..
...Дүрт ягы да кыйбла булучылар
Канатларга тугры кала микән?..

* * *

Эткә сөяк ташлагандай кар коела,
Таш урамнар ялый бара һәр бөртеген...
Сукмакларда сыкрап калыр сары яфрак,
Узар кемдер, ашыктырып үз бетемен.

Кул чабарлар алгысынып канатсызлар,
Чыда гына аклыгына – беренче кар!..
Беренчесе булган кебек, карларның да
Соңгысы бар, соңгысы бар, соңгысы бар...

Ә әлегә чыдыйсы бар чуарлыкка,
Куырылып каласы бар сорылыктан.
...Эткә сөяк ташлагандай кар коела,
Урамнарга ак төш иңә ак болыттан...

* * *

Чынбарлыкка чыныкмаган чаклар,
Абынмаган чаклар сыңарлыкка...
Күмерләргә күмелмәгән күңел
Сынауларда әле сынарлык та,
Чыдарлык та чыклы чакрымнарга –
Тойгыларда табу тагылмаган...
Без
урыйсы
юллар еракпыгын
Чикләүчеләр әле табылмаган...

* * *

Ә карлар төш күрә офыкта…
Карасы бар микән карларның?..
…Берни дә булмады,
Син генә,
Син генә үз итеп карадың…

Ә карлар төш күрә офыкта…
Нинди төш керәдер карларга?
…Берни дә булмаган
…Һәм син дә…
Үз итеп,
Күз итеп карама…

* * *

Син – тораташ калган таң сурәте,
Күзләреңдә томан төсмере…
Көләч язлар көзгеләрдә калган –
Без язларның үзе төслеме?..

Җирдән күккә, әллә күктән җиргә
Яфрак-яфрак җаннар күчтеме?..
…Җир җиләген көзен эзләмиләр –
Без көзләрнең үзе төслеме?..

* * *

Телем-телем кояш тәрәзләрдә...
Дөнья исе килә дөньялыктан...
Җан тыелып кына тын алганда,
Җиләс җүләрлеген Кем оныткан?..

Җиләк булып җиргә төшеп калган
Кайнарлыгын тоеп узган язның...
...Яңгыр аша дәште кебек Кемдер:
«Мин ялгышып кына... яши яздым...»

* * *

Мең чыбыркы ысылдавы җилдә
Хәрабәләр һәйкәл булган илдә.
Таң атышлый гына кояш бата...
Сибелә генә чәчәк, сибелә җилгә...

Көл өстенә гөлләр сибү фалы
Меңьеллыклар белән саналамы?..
Бабалардан калган калаларда
Дөнья авыш микән, манарамы?..

Сискәнеп бер уянырбыз микән
Аягүрә килеш күргән төштән?..
Тышауланган чорлар ияренә
Чал сакаллы хәтер чалкан төшкән...

Заман әле зарсыз, аңсыз гына
Биле сынык туган таен сата...
Бездә шундый иләс тынлык әле,
Таң атышлый гына кояш бата...

* * *

Яланаяк язлар китә бездән,
Китә безне сукмыйча да санга.
Керфекләргә офык терәлгәндә,
Парә-парә пәрдә элик җанга...

Чынбарлыкның чылбырлысы көтә
Чәбәләнгән җаннар чатырыннан.
Яланаяк язлар китә бездән,
Ашыгылган кебек, ашыгылган...

* * *

Җирдән – күккә, күктән җиргә кадәр
Кадакланган ачык тәрәзәләр.
Тәрәзләрдән таңда Тәңре карый.
Ә пәрдәләр зәңгәр.

Акшарланган күккә, кара җиргә
Артык килешле күк шушы чалым...
Җирдән – күккә, күктән җиргә кадәр
Дөньялыкның бүген бикле чагы...

Җирдә туфрак катмар-катмар, диләр,
Күкләр җиде катлы...
...Ә кешеләр бәхет диеп атый
Аяк асларыннан җир шуышкан
Һәм күк капусы ачылган бер чакны...

...Иңләгәндә хәят җирне, күкне,
Дөньялыктан нидер саный-саный,
Пәрдәләре зәңгәр ачык тәрәзләрдән
Акрын гына таңда Тәңре карый...

* * *

...Кайдадыр.
Кандагы кайнарлык – кыраулы.
Һәр караш кадалып яралый.
Җаннарга яшеннәр дәшкәндә
Еларга ярамый, ярамый...
Кемгәдер
Ярлыкау – ятлыктан бер йолку,
Бер йолу.
Йоласы ничектер бу якта...
Читләтеп үтелер юлларның тузанын
Сагыну сусавы уята.
Аякта чакларда, таяклар – мескенлек.
Без килдек, без күрдек, без җиңдек!..
Ничектер
Кичекми
Кайтасы иде бит,
Каядыр кайтасы иң элек...

* * *

Чиксезлек турында пышылдап,
Урамнар ураган
Җил генә.
Читләтеп чигелгән чакларым
Чиксезлек чигенә...
Үзәккә үтәрлек үгилек.
Тартылам, тайпылам, талпынам...
Җил дә юк, ил дә юк, МИН дә юк...
...Тын урам.

* * *

Кырыйдан карадым, кырыйлап карадым –
Кыргыйлык үземдә, үзәктә...
Үз итә алсам да, кадерле калсам да,
Алалмам үзгәртә...

Җанкаем,
Җай гына таң җиле искәндә,
Җәй генә уяна дисеңме...
Үзәктән үзәккә өзлексез үрелеп,
Уяна шул Хиснең исеме...

Тантана!
Бөек Ау вакыты башлана!
Исерек иләслек ят аңа...
Сунарчы җаннарда сүрелгән кыргыйлык
Кайрылып уяна һәр таңда...

* * *

Хәнҗәрләр хәтере – хакыйкать.
Хак кушкан хаклык бар,
Хаклык бер!..
Кан исе, җан исе, көч хисе, буталып,
Чорларны укшытыр барыбер...

Кадерле кан бит ул, каберсез җан бит ул,
Хис бит ул – кыргыйлык, затлылык...
Бербөтен дәвамның бөтен бер өлеше –
Яшәргә, яшәргә хаклылык.

Бу – тәүге һәм соңгы хакыйкать,
Хак кушкан хаклык бу, бердәнбер...
Изге кан игез җан юлыннан
Хәнҗәрләр йөзендә йөргәндер...

Кындагы хәнҗәргә каныккан
Карлыккан тавышлы хәтерме –
Каннарда кайтаваз котыра:
«Хәтерлим! Хәтерлим!!!»
Хәтер Мин...

* * *

Минсезлек.
Мин минсез калада.
Карлыгач очышы көнозын.
Табынсаң – тайпылма,
Талпынма...
«Бәхетең булсын ла, и кызым...»

Күзләрең төннәрдән карарак,
Кашларың – карлыгач канаты.
Яшәрсең йөрәгең канатып,
Уйларың еракка җан атыр,
Карлыгач очышын күзәтсәң...

Сүз әйтмәм,
Сүз әйтмәм, үзгәртмәм,
Талпынып син карап калганда...
...Карлыгач очышы көнозын.
Минсезлек
Мин-минсез калада...

* * *

Барлы-юклы дөнья киңлегендә
Киерелеп очкан киек кош син.
Исемеңне күкләр белә булыр...
Ә дөньялык бүген син ишесен
Киеменә карап каршы ала.
Килгәннәргә монда шундый кадер:
Киңлекләрне кисемтәләп кисү
Сабыйлыктан карыйлыкка кадәр...

Диварларда диваналар елъязмасы,
Акшарланган күкләр түшәм бүген.
Тынлык сыймас тарлык...
Яңа тарих. Яңа исем туар дүшәмбедән.

Ул исемне күкләр күкрәп кушар –
Яңа исем синең киемеңә...

Киерелеп очкан киек кош без
Барлы-юклы дөнья киңлегендә...

# Эчтәлек


Табигать кызы. *Л.Шәех* . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
«Эх!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
«Җир караңгы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
«Соры томан арада...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
«Аклык...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
«Ак болыт юллары һавада...» . . . . . . . . . . . . . 7
«Төн инде...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Кагылма син аңа...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
«...Ә очасы килә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
«Яндыр әле ялкынында, яңгыр!..» . . . . . . . . . . 11
«Яшьләреңдә – узган еллар кере...» . . . . . . . . . 11
«Ярым ташу...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Җирдә әле көзләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«...Еракта бу тынлык...» . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Сорылыкка сарылды да...» . . . . . . . . . . . . . . 14
«Бу җиһан, бу галәм, бу җирдә...» . . . . . . . . . . 15
«Сукыр җырчы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
«Вакыт үзе чиксез бер мизгел...» . . . . . . . . . . 17
«Мин язларны сиңа бүләк итәм...» . . . . . . . . . . 18
«Мин язларга яланаяк чабам...» . . . . . . . . . . . 18
«Бу – кояшлы төнме...» . . . . . . . . . . . . . . . . 19
«Пәрәвез җебендә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Ачык тәрәзәләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Дулкын-дулкын упкын...» . . . . . . . . . . . . . . 21
«Йөрәгемне урталайга телә...» . . . . . . . . . . . . 21
«Күкләр биек...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
«Бәхетем тузаны, томан күк...» . . . . . . . . . . . 23
«Тын алуым, соңаруым аша...» . . . . . . . . . . . . 24
«...Ә син мине ярат!..» . . . . . . . . . . . . . . . . 25
«Күкнең күкрәгенә хәнҗәр кадап...» . . . . . . . . . 25
«Шартлап Вакыт өзелерлек Тынлык...» . . . . . . . 26
«Син мине очарга өйрәт тә...» . . . . . . . . . . . . 27
«Томан түгел, төсләр төенләнгән...» . . . . . . . . . 28
«Кыйгач-кыйгач болыт күктә генәй!..» . . . . . . . . 28
«Эткә сөяк ташлагандай кар коела...» . . . . . . . . 29
«Чынбарлыкка чыныкмаган чаклар...» . . . . . . . . 29
«Ә карлар төш күрә офыкта...» . . . . . . . . . . . . 30
«Син – torаташ калган таң сурәте...» . . . . . . . . 30

«Телем-телем кояш тәрәзләрдә...» . . . . . . . . . . . 31
«Мең чыбыркы ысылдавы җилдә...» . . . . . . . . . 31
«Яланаяк язлар китә бездән...» . . . . . . . . . . . . 32
«Җирдән – күккә, күктән җиргә кадәр...» . . . . . . 32
«...Кайдадыр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Чиксезлек турында пышылдап...» . . . . . . . . . . 33
«Кырыйдан карадым, кырыйлап карадым...» . . . . 34
«Хәнҗәрләр хәтере – хакыйкать...» . . . . . . . . . . 35
«Минсезлек...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Барлы-юклы дөнья киңлегендә...» . . . . . . . . . 37

Литературно-художественное издание

**Гибадуллина** Лилия Фаисовна

Эхо тишины

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Гыйбадуллина** Лилия Фаис кызы

Тынлык кайтавазы

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Г.Зиннәтуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.05.2010.
Форматы 70×84 1/32. Шартлы басма табагы 1,36.
Тиражы 1000 д. Заказ В-916.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.